**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 5 мартындагы 529 номерлы карары**

## 2025 елга гражданнар керемене һәм салым салынырга тиешле милек хакының чик күрсәткечләрен раслау турында

Россия Федерациясе Торак Кодексының 14 статьясы, 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы «Гражданнарның Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль яллау килешүләре буенча торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында»гы Татарстан Республикасы Законы, әлеге законның кушымтасында бирелгән һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданинга туры килә торган керемнең чик күрсәткечләрен һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче гражданин милкендәге һәм салым салынырга тиешле милек хакын билгеләү методикасы нигезендә, шулай ук Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 40 статьясына таянып, **карар бирәм**:

1. 2025 елга гражданнарны аз керемлеләр дип тану турында карар кабул итү өчен түбәндәге чик күрсәткечләрен билгеләргә:

1.1. гаилә әгъзалары милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чиге:

1.1.1. ялгыз яшәүче гражданин өчен – 2 550 312,0 сум;

1.1.2. ике кешелек гаилә өчен – 5 100 624,0 сум;

1.1.3. өч кешелек гаилә өчен – 7 650 936,0 сум;

1.1.4. дүрт кешедән торган гаилә өчен – 10.201 248,0 сум;

1.1.5. биш кешедән торган гаилә өчен – 12 751 560,0 сум;

1.1.6. алты кешелек гаилә өчен – 15 301 872,0 сум;

1.1.7. җиде кешелек гаилә өчен – 17 852 184,0 сум;

1.1.8. сигез кешелек гаилә өчен – 20 402 496,0 сум;

1.1.9. тугыз кешелек гаилә өчен – 22 952 808,0 сум;

1.1.10. ун кешедән торган гаилә өчен – 25 503 120,0 сум;

1.1.11. унбер кешелек гаилә өчен – 28 053 432,0 сум;

1.1.12. унике кешедән торган гаилә өчен – 30 603 744,0 сум;

1.2. гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданинга туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләме – 48 245,0 сум.

2. Казан шәһәре Башкарма комитетының район администрацияләре башлыклары Р.Х.Шәмсетдиновка, А.И.Салиховка, В.В.Жаворонковка һәм Р.Р.Фәтхетдиновка гражданнарны социаль яллау килешүләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә куйганда әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктларында күрсәтелгән чик күрсәткечләрен файдаланырга.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Ә.Гыйниятуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**